РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 октябрь, 2024 ел № 180

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 июлендәге 153 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 енның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары нигезендә, Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 июлендәге 153 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1.5 пунктында:

- бишенче абзацта «Россия Федерациясе субъекты,» сүзләреннән соң «федераль территория,» сүзләрен өстәргә.

- сигезенче абзацта «(шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы),» сүзләреннән соң «яр буе,» сүзен өстәргә.

- тугызынчы абзацта «яр буе,» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче В.Н. Андреев